# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2015 елның 30 декабре №31

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 12.06.2002 елгы № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында»гы 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдумны үткәрүне оештыру турында»гы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге 89 номерлы карары, Бишнә авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 декабрендагы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 2016 елның 6 мартына Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. 2016 елда Бишнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешегә 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Төзү, агымдагы һәм капиталь ремонт - автомобиль юллары, ишегалды территорияләре , кварталара юлларны тоту | 80000 |

«ӘЙЕ» «ЮК».».

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**